ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6[1] статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6[1] статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), «күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре ризалыгы белән торак урыннарга кереп йөрүгә һәм аларны өйрәнүгә» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре, социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар ризалыгы белән күпфатирлы йорттагы мондый урыннарга кереп йөрүгә һәм аларны өйрәнүгә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 25-ТРЗ